ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.10.2023 г. Казань **№** 741/2023

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау хакында» 20.10.2017 №284 боерыгына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 3 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау хакында» 20.10.2017 №284 боерыгына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 31.05.2019 №142, 20.11.2021 №731/2021, 11.02.2022 №36/2022 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 18.11.2010 №906 карары нигезендә;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәдә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары каршындагы» сүзләренә алыштырырга;

3.1 пунктта «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары каршындагы» сүзләренә алыштырырга;

5.3 пунктның икенче кызыл юлын түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук Дәүләт комитеты инициативасы белән Дәүләт комитеты тарафыннан эшләнгән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарында эшләнә торган, әлеге башкарма хакимият органнары карамагындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышусыз кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар составын раслау турында» 2013 елның 29 мартындагы 214 номерлы карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарында эшләнә торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар исемлегендә каралган, әлеге башкарма хакимият органнары карамагындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышусыз кабул ителә алмый торган норматив хокукый актларның проектларына һәм Дәүләт комитетының билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрелә торган норматив хокукый актларына Иҗтимагый совет бәяләмәсе бирү максатларында да үткәрелә.».

2. Бу боерык аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина